| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА НОВОМАЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>МЕНЗЕЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МИНЗƏЛƏ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНА ЯҢА МАҖЫН АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 2** **09 октябрь 2022 ел**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге составына керүче Яңа Маҗын торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 09 октябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Минзәлә муниципаль районының Яңа Маҗын авыл җирлеге Яңа Маҗын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме,I һәм 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы,сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Чернобыль АЭС ликвидациясендә катнашучылардан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Юл эшчәнлеге, Яңа Маҗын торак пунктында Яшьләр, Заречная, Болынлы, Коммунистик урамнарында юл эшчәнлеге, ком-гравий катнашмасы сибү (килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 190 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 145 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында 145 катнашучы "РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Маҗын авыл җирлегенең Яңа Маҗын торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

Әлеге сорау буенча карар кабул ителде: "Минзәлә муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлеге Яңа Мажын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме,I һәм 2 группа инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы,сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Чернобыль АЭС ликвидациясендә катнашучылардан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокл хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Юл эшчәнлеге, Яңа Мажын торак пунктында Яшьләр, Заречная, Болынлы, Коммунистик урамнарында юл эшчәнлеге, ком-гравий катнашмасы сибү (килешү буенча эшләр өчен түләү).

2. Яңа Мажын авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында - http://menselinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan аны урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итергә http://menselinsk. tatarstan.ru.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгы И.А.Колбин